**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 21 декабрь | № 962

г. Казань

«2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетын 2016 елның 1 гыйнварыннан үтәү өчен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторларына:

Татарстан Республикасы бюджетына салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр килүне тәэмин итү, шулай ук аларны түләү буенча бурычларны киметү буенча чаралар күрергә;

квартал саен Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы билгеләгән вакытларда һәм форма нигезендә ай саен керемнәр керү фаразларын кертергә;

керемнәр буенча бюджетның фактлагы үтәлеше фаразда каралганнан тайпылу сәбәпләрен күрсәтеп, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы билгеләгән вакытларда керемнәр өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында квартал саен аналитик материаллар кертергә;

үз ведомстволары буйсынуындагы бюджет керемнәре администраторлары исемлекләрен билгеләү турында норматив хокук актлары кабул итүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына квартал саен Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы билгеләгән вакытларда һәм форма нигезендә, элек бирелгән бюджет кредитларын каплауга күздә тотылган акчаны кире кайтару суммаларын исәпкә алып, чираттагы кварталга Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын эчке һәм тышкы финанслау чыганаклары акчасын каплау һәм ай саен җәлеп итү фаразларын кертергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр

округларының җирле үзидарә органнарына җирле бюджетларны үтәү турындагы мәгълүматны, бу карарның 2 нче пунктындагы өченче, дүртенче абзацларда һәм 3 нче пунктында күздә тотылган шундый ук мәгълүматны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.

5. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

субвенцияләр, субсидияләр, максатчан билгеләнешкә ия булган башка бюджетара трансфертлар рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына һәм җирле бюджетларга бирелгән, 2016 елның 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмый калган бюджетара трансфертлар 2016 елда беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш дип;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр федераль башкарма хакимият органнарына кертә торган бюджетара трансфертлардан файдалану турындагы хисаплар Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән килештерелергә тиеш дип;

бюджетара трансфертлардан кайтарудан Татарстан Республикасы бюджетына кремнәрне администрацияләүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары тарафыннан 2015 елда алынган һәм файдаланылмаган субсидияләр рәвешендә алынган  бюджетара трансфертларга һәм бүтән максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу (булмау) турында карар кабул ителергә, шулай ук 2016 елда шул ук максатларга юнәлтү ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән бюджетара трансфертларны алар тарафыннан Татарстан Республикасының территориаль мәҗбүри медицина иминиятләве фонды бюджетына кире кайтару бюджет акчасының баш администраторы билгеләгән тәртиптә формалашкан  тиешле бюджет чыгымнары турында хисапны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге акча Татарстан Республикасы бюджетына кергән көннән соң 30 календарь көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырылырга тиеш дип;

социаль-мәдәни өлкә һәм торак-коммуналь хуҗалык объектларын дәүләт милкеннән муниципаль милеккә тапшыру, агымдагы елда тапшырылган объектларның эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнарын каплау чыганагын билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокук актлары нигезендә гамәлгә ашырыла дип.

6. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм дәүләт казна учреждениеләре булган дәүләт заказчыларына товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән, дәүләт контрактларына түләүгә әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2015 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең калган өлешләре турында 2016 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына мәгълүмат кертергә.

7. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2015 елда түләнергә тиешле дәүләт контрактларына түләүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең

файдаланылмый калган өлеше суммасы чикләрендә 2016 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре турында 2016 елның 15 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә.

8. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына:

2015 елның 25 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының чыгымнар буенча 2016 елда Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән норматив хокук актлары проектларын билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

«2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре һәм дәүләт хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган тәкъдимнәр кертмәскә.

9. 2017 елның 1 гыйнварына кадәр түбәндәгеләрне эшләү рөхсәт ителми:

эш хакы буенча бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән тәртиптә расланган лимитларын агымдагы финанс елында башка максатларга күздә тотылган бюджет йөкләмәләре лимитларын файдалану буенча экономия хисабына арттыру; моңа Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләнә торган акчаны түләүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары керми;

хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләнә торган акчаны түләүгә билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитларын башка максатларга күздә тотылган бюджет йөкләмәләре лимитларын арттыру максатларында киметү, моңа эш хакы буенча бюджет йөкләмәләре лимитлары керми.

10. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру буенча конкурста, аукционда катнашуга гаризаларны тәэмин итү сыйфатында торгларда катнашучылар кертә торган акча, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен сатып алуларда катнашучылар Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары үтәлешен тәэмин итү сыйфатында кертә торган акча, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен сатып алуларда катнашучылар торгларда катнашуга гаризаны тәэмин итү сыйфатында кертә торган акча суммалары алар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында учреждениеләрнең вакытлыча карамагына керә торган акча белән башкарыла торган операцияләрнең исәбен алу өчен ачкан Татарстан Республикасы учреждениеләренең шәхси исәпләрендә исәпкә алына дип билгеләргә.

11. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына бюджет акчасы белән баш эш итүчеләргә 2016 елга Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет исемлегендә билгеләнгән күләмдә бюджет ассигнованияләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары турында хәбәрнамә җибәрергә.

12. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләргә:

үзләренә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм җыелма бюджет исемлегенең расланган күрсәткечләре нигезендә бюджет йөкләмәләре лимитларын

ведомство буйсынуындагы эш итүчеләр һәм (яки) Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучылар арасында бүләргә;

максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара трансфертлар биргәндә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә бюджетлар арасындагы исәп-хисаплар буенча хәбәрнамәләр җиткерергә.

13. Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучылар Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр (дәүләт контрактлары) төзегәндә түбәндәге аванс түләүләрен күздә тотарга хокуклы дип билгеләргә:

шартнамә (контракт) суммасының 100 процентына кадәр күләмдә – ягулык-майлау материаллары, транспорт чаралары, юлламалар, авиа- һәм тимер юл билетлары, шәһәр һәм шәһәр яны транспорты белән бару өчен билетлар, ашыгыч әһәмияткә ия булган медикаментлар (кеше тормышы өчен куркыныч янаган хәлләрдә кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү өчен таләп ителә торган медикаментлар) сатып алу шартнамәләре (контрактлары), Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы чит ил оешмалары белән төзи торган Россия Федерациясе гражданнарына Россия Федерациясе территориясеннән читтә дәвалау үткәрү турындагы шартнамәләр, белем алу (эштән азат ителү куркынычы янаган хезмәткәрләргә, инвестиция проектлары нигезендә җитештерүне реструктурлаштыру һәм модернизацияләүне гамәлгә ашыручы җитештерү өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә белем бирү (квалификация күтәрү, һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү, алдан әзерләү, зарарлы җитештерүдән чыгару максатларында, хезмәт шартлары зарарлы һәм авыр булган хатын-кызларга алдан һөнәр белеме бирү) хакындагы, басма матбугатка язылу турындагы, элемтә, кабельле һәм спутник телевидениесе хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамәләр, биналарны арендалау, мөлкәтне иминләштерү турындагы шартнамәләр, проектлау документларына дәүләт экспертизасы үткәрү, мәгълүмат белән тәэмин итү, транспортта йөртү хезмәтләре күрсәтүгә түләү хакындагы шартнамәләр, фәнни, мәдәни, экскурсия һәм спорт чаралары үткәрү турындагы шартнамәләр буенча;

шартнамә (контракт) суммасының 30 процентына кадәр күләмдә – Россия Федерациясе законнары белән башкасы күздә тотылмаса, калган шартнамәләр (контрактлар) буенча.

14. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә сарыф ителә торган субсидияләрне муниципаль берәмлекләргә күчерүне Россия Федерациясенең сатып алулар өлкәсендәге контракт системасы турындагы законнары нигезендә төзелгән контракт (шартнамә) булганда түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырырга:

контрактта (шартнамәдә) билгеләнгән күләмдә – аванс түләү өчен;

эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне, товар кайтартуны раслый торган документлар булганда – контракт (шартнамә) буенча башкарылган эшләргә, күрсәтелгән хезмәтләргә, кайтартылган товарга түләү өчен.

15. Товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш (алга таба – юридик затлар), шәхси

эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү 2016 елда түбәндәге нигезләмәләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла дип билгеләргә:

а) әгәр дә норматив хокук актлары белән башкасы күздә тотылмаса, субсидияләр, бер яктан, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр һәм, икенче яктан, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче юридик затлар шәхси эшмәкәрләр яки физик затлар тарафыннан төзелә торган, түбәндәге шартларны күздә тотучы шартнамәләр (килешүләр) нигезендә бирелә:

субсидияләрне күчерү вакытлары (шул исәптән финанслар белән тәэмин ителү чыганагы агымдагы финанс елы эчендә файдаланылмый калган субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге булу (булмау);

товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче юридик затның (үзләренең устав (тупланма) капиталларында гавәми-хокукый оешмалар катнашында дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр, хуҗалык итүче иптәшлекләр һәм җәмгыятьләрдән, шулай ук үзләренең устав (тупланма) капиталларында мондый иптәшлекләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерциячел оешмалардан тыш), шәхси эшмәкәрнең яки физик затның әлеге шартнамәдә (килешүдә) билгеләнгән субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе (кагыйдәләре) үтәлүне ачыклау буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органнары тарафыннан тикшерүләр үткәрүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче, шулай ук дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органнары үткәргән тикшерүләр йомгаклары буенча субсидияләр бирүнең тиешле тәртибе (кагыйдәләре) һәм күрсәтелгән шартнамә (килешү) белән билгеләнгән максатлар һәм шартлар бозылу фактлары ачыкланса, товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче юридик зат, шәхси эшмәкәр яки физик зат файдаланган суммаларны кире кайтару тәртибе;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылык кертүнең Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән килештереп билгеләгән тәртибе һәм вакытлары;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешен кире кайтару тәртибе;

финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидияләр бирелә торган чыгымнар исемлеге;

б) субсидияләрне күчерү, әгәр дә башкасы субсидияләр бирү тәртибен (кагыйдәләрен) билгели торган норматив хокук актлары яки килешүләр (шартнамәләр) белән күздә тотылмаса, субсидияләр алучыларга (товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, физик затларга), Россия Федерациясе Үзәк банкының исәп-хисап челтәре бүлекчәләрендә яки кредит оешмаларында ачылган хисап исәпләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән тиешле баш эш итүче тарафыннан билгеләнгән форма буенча һәм вакытларда гаризалар һәм (яки) хисаплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

16. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

тиешле бюджет кредитлары буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы алдындагы йөкләмәләрен (бурычларын) реструктуризацияләү белән бәйле Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән файдаланган өчен түләү күләме үзгәрүгә бәйле Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджет кредитлары бирү турында элек төзелгән килешүләргә үзгәрешләр кертү («2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясындагы 4 өлеш) Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының тәкъдиме (гаризасы) нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты арасында төзелгән, шул исәптән бурычны түләү графигын үзгәртүне күздә тоткан өстәмә килешү төзү юлы белән гамәлгә ашырыла;

төзелгән өстәмә килешүләр Казан шәһәре Думасы карары белән раслана, аның күчермәсе өстәмә килешү имзаланган көннән соң 3 ай эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына җибәрелә.

17. Бу карарга теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә 2016 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары гамәлен озайтырга.

18. Бу карарга теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән аерым нормалары гамәлен 2016 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр туктатып торырга.

19. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\962.docx